Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлегенең Мордыбый торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 06 декабрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясынигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге Мордыбый торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, иректән мәхрүм ителгән физик затлардан тыш, Тирсә авыл җирлеге Мордыбый авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
   - Мордыбый авылы территориясендә урам юлларын карап тоту
   - Мордыбый авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен скважина бораулау
3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Тирсә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек Башлыгы Р.Р. ЗАКИРОВ

Совет Терсинского сельского поселения
Тирсә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002597
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ